Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Аппак авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел N 4

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Илтән-Бота авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль района Аппак авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 13 ноябрендә, 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең Илтән-Бота авылында урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 13 ноябрендә 19 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең Илтән-Бота авылында Комсомол, Түбән, Болын, Жиңү, Кыр, Елга, Яңа урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Аппак авыл җирлегенең Илтән-Бота авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Илтән-Бота авылы зираты территориясен төзекләндерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Халык җыены этапларын Илтән-Бота авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Илтән-Бота авылы, Совет урамы, 71 нче йортта уздырырга.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең Илтән-Бота авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Илтән-Бота авылы, Совет урамы, 71 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Аппак
авыл җирлеге башлыгы В.Н. Горбунова